# КҮЗЛӘРЕҢНӘН КҮЗЕМ АЛМЫЙМ

*ЛУИЗА БАТЫРКАЕВА музыкасы*
*ФӘЙРҮЗӘ МӘСЛИМОВА сүзләре*

Тамчы булып чәчләреңә
Уйнап тамасым килә.
Күңелеңдә ләйсән булып
Урын аласым килә.

*К у ш ы ы т а:*
Күзләреңнән күзем алмый
Карап торасым килә.
Үзем яраткан кадәрле
Яраттырасым килә.

Коштай очып, кочагыңа
Бер атыласым килә.
Иркәләнеп, бер мизгелгә
Онытыласым килә.

*К у ш ы м т а.*